**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 ел, 21 октябрь № 790

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Граждан хәле актларын язу идарәсе коллегиясе составы турында» 2008 ел, 27 март, 192 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2008 ел, 31 декабрь, 954 нче; 2009 ел, 8 октябрь, 688 нче; 2011 ел, 26 апрель, 337 нче; 2012 ел, 7 август, 671 нче; 2014 ел, 1 февраль, 55 нче; 2014 ел, 30 декабрь, 1070 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Граждан хәле актларын язу идарәсе коллегиясе составына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

коллегия составыннан Г.И.Сергееваны, Б.Т.Хафизовны чыгарырга;

коллегия составына түбәндәгеләрне кертергә:

Виктор Николаевич Демидовны, Россия Федерациясе Юстиция министрлыгының Татарстан Республикасы буенча идарәсе башлыгын (килешү буенча);

Флюра Әмир кызы Илдархановaны, Татарстан Республикасы Фәннәр акамедиясенең Татар энциклопедиясе һәм төбәкләрне өйрәнү институтының Гаилә һәм демография үзәге җитәкчесен, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Граждан хәле актларын язу идарәсе каршындагы иҗтимагый совет рәисен (килешү буенча).

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Граждан хәле актларын язу идарәсе мәсьәләләре» 2007 ел, 7 ноябрь, 614 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2009 ел, 15 июнь, 386 нчы; 2010 ел, 9 июнь, 453 нче; 2010 ел, 17 декабрь, 1078 нче; 2011 ел, 13 май, 379 нчы; 2011 ел, 9 август, 645 нче;

2012 ел, 29 ноябрь, 1045 нче; 2013 ел, 12 март, 158 нче; 2013 ел, 31 октябрь, 812 нче; 2014 ел, 26 ноябрь, 918 нче; 2015 ел, 23 июнь, 457 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Граждан хәле актларын язу идарәсе турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

5.3 нче пунктның икенче абзацына «Идарәнең структур бүлекчәләре җитәкчеләре» сүзләреннән соң «, Идарә каршындагы Иҗтимагый совет рәисе» сүзләрен өстәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2015\790.docx